| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2021 № 1076

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елның 2 яртыеллыгына торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2021 елның 22 июнендәге 810 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында»» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 28 июнендәге 506 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елның 2 яртыеллыгына торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2021 елның 22 июнендәге 810 номерлы карарының 1 нче кушымтасындагы 4 пунктына үзгәрешләр кертеп түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә.

| № т/н | Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү үлчәү бердәмлегендә (аена), сум. | Хезмәт күрсәтүгә үлчәү берәмлегенең тарифы (сум). |
|---|---|---|---|
| | | | 01.07.2021 елдан башлап 31.12.2021 елга кадәр |
| 4 | Торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү) | торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 6,38 |

2. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш һәм гамәлдә булу чоры 2021 елның 1 июленнән башлап барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов